МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

№ 91/о

БОЕРЫК

«15» 06 2015

**Юридик затларга чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында гариза, килешү рәвешләрен раслау хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 3 июнендәге "Юридик затларга төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә күргәзмәләр, корылтайлар, конференцияләр, симпозиумнар, съездлар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау хакында" 404 номерлы карарын үтәү максатларында **б о е р а м:**

1. Кушымта булып килүче түбәндәгеләрне расларга:

төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә күргәзмәләр, корылтайлар, конференцияләр, симпозиумнар, съездлар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия алу өчен гариза рәвешен (алга таба – гариза, субсидия, тиешенчә);

төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә күргәзмәләр, корылтайлар, конференцияләр, симпозиумнар, съездлар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия алу өчен Килешү рәвешен (алга таба – Килешү).

2. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә күргәзмәләр, корылтайлар, конференцияләр, симпозиумнар, съездлар оештыру һәм үткәрү белән бәйле гаризаларны кабул итү вакытын – чараны үткәргән датадан соң 6 (алты) ай дәвамында итеп билгеләргә.

3. Дәүләт сатып алулары секторы җитәкчесенә (В.Н. Грязновага) билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

юридик заттан гаризаны кабул итү һәм теркәү;

тапшырылган документларга анализ ясау һәм субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрү;

юридик затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан Килешүгә имза салу.

4. Дәүләт программаларын финанслау бүлеге башлыгына (Н.В. Зайцевага) билгеләнгән тәртиптә, бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре чикләрендә, алучыга субсидияләр күчерүне тәэмин итәргә.

5. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесенә (Г.С. Миңнехановага) әлеге боерыкның күчермәсен, теркәгәннән соң бер эш көне дәвамында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Юридик бүлеккә (Э.Ю. Латыйповага) боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына җибәрергә.

7. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Ф.М. Хәнифовка йөкләргә.

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

ОТДЕЛ
РЕГЛАМЕНТА
И КОНТРОЛЯ
№1

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалык
министрлыгының 2015 елның
15 июнендәге 91/о номерлы
боерыгы белән расланды

Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә күргәзмәләр, корылтайлар, конференцияләр, симпозиумнар, съездлар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия алу өчен

**___ номерлы**

**КИЛЕШҮ**

Казан ш. «____» ____________201_ ел.

Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, алга таба “Министрлык” дип исемләнә, Нигезләмә нигезендә гамәл кылучы министр_______________________ исеменнән, бер тарафтан, һәм алга таба “Алучы” дип исемләнүче ___________________________, _______________________ нигезендә гамәл кылучы___________________ исеменнән, икенче тарафтан, икесе бергә “Тарафлар” дип исемләнүчеләр, түбәндәгеләр хакында әлеге Килешүне төзеде:

## 1. Килешүнең предметы

1.1. Министрлык тарафыннан Алучыга Татарстан Республикасы бюджетыннан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә күргәзмәләр, корылтайлар, конференцияләр, симпозиумнар, съездлар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплау буенча __________________________________ өчен (*чараның исемен күрсәтергә*) (алга таба – чара, субсидия, тиешенчә) субсидия бирү әлеге Килешүнең предметы булып тора.

## 2. Тарафларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Алучы түбәндәгеләрне бурычлы:

2.1.1. Килешү үтәлгән чорга гамәлдә булган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларының таләпләре нигезендә субсидияне аның максатчан билгеләнеше буенча тотарга;

2.1.2. Килештерелгән сметаны исәпкә алып, субсидия күчү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбе алып барырга (1 кушымта);

2.1.3. Субсидияне алган датадан соң 1 (бер) айдан да соңга калмыйча Министрлыкка субсидияне файдалану турында хисап тапшырырга (2 кушымта);

2.1.4. Түләү реквизитлары үзгәргән очракта, 5 (биш) эш көне дәвамында, яңа реквизитларны күрсәтеп, вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган язмача хәбәрнамә җибәрү юлы белән, кичекмәстән Министрлыкка хәбәр итәргә. Алучы тарафыннан реквизитлар дөрес күрсәтелмәгән очракта, Министрлык тарафыннан әлеге Килешүдә күрсәтелгән исәп-хисап счетына акча күчерүгә бәйле барлык куркынычлар өчен Алучы үзе җаваплы була;

2.1.5. Алучының субсидия бирелү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан тикшерүләр өчен шартлар тудырырга;

2.1.6. Министрлык, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы таләбе буенча, алар тарафыннан билгеләнгән срокларда, әлеге Килешүнең үтәлүен контрольдә тоту өчен кирәкле булган мәгълүматны һәм документларны тапшырырга;

2.1.7. Әлеге Килешүне тиешенчә үтәү өчен каршы килә торган шартлар турында Министрлыкка үз вакытында хәбәр итәргә;

2.2. Министрлык түбәндәге йөкләмәләрне ала:

2.2.1. Министрлык өчен расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, әлеге Килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокта, чараны оештыру һәм үткәрү өчен килештерелгән чыгымнар сметасын исәпкә алып, субсидияне күчерергә;

2.2.2. Субсидиянең максатчан һәм нәтиҗәле файдаланылуын контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2.3. Законнарда билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән берлектә, субсидия бирелү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тотарга.

2.3. Алучы әлеге Килешүдә каралган максатларга, тәртиптә һәм шартларда субсидияне күчерүне таләп итәргә хокуклы.

2.4. Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Министрлык әлеге Килешүгә кирәкле үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертү хокукына ия.

## 3. Исәп-хисап ясау тәртибе һәм шартлары

3.1. Чараны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарның килештерелгән сметасын (1 кушымта) исәпкә алып, финанслауның гомуми күләме _________________ (*субсидия күләмен күрсәтергә*) тәшкил итә.

3.2. Әлеге Килешүнең 3.1 пунктында күрсәтелгән күләмдә субсидия акчаларын күчерү Министрлыкның Федераль казначылык органында ачылган исәп-хисап счетыннан Алучының кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына күчереп башкарыла.

3.3. Министрлык, субсидия бирү турында Килешү төзелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнүче 14 көнлек срокта, билгеләнгән тәртиптә, субсидияне субсидия алучының кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына күчерә.

## 4. Тарафларның җаваплылыгы

4.1. Килешү буенча бурычлары үтәлмәү яки тиешенчә үтәлмәү очрагында Тарафлар Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы була.

4.2. Законнарда билгеләнгән очракларда, Министрлыкның тиешле таләбе буенча, эш көннәрендә исәпләнүче 30 көнлек срокта, Алучы тарафыннан субсидия кире кайтарып бирелергә тиеш.

4.3. Күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты кереме хисабына ирекле кайтарып бирүдән баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә кайтарып бирелергә тиешле.

## 5. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

5.1. Әлеге Килешү буенча яки аңа бәйле рәвештә Тарафлар арасында барлыкка килә торган бәхәсле мәсьәләләр Тарафлар арасында сөйләшүләр алып бару юлы белән хәл ителә.

5.2. Әлеге Килешүне үтәгәндә яки аңа бәйле рәвештә барлыкка килгән, Тарафлар тарафыннан җайга салынмый торган бәхәсләр һәм аңлашылмаучанлыклар Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә хәл ителә.

## 6. Килешүнең гамәлдәге вакыты

6.1. Әлеге Килешү Тарафлар аңа имза салганнан соң үз көченә керә һәм ________________ кадәр гамәлдә була.

## 7. Йомгаклау нигезләмәләре

7.1. Субсидия Алучы тарафыннан субсидия бирелү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен Министрлык, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан тикшереп торуларга субсидия Алучының ризалык бирүе әлеге Килешүнең мәҗбүри шарты булып тора.

7.2. Тарафлар тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәнчә язмача рәвештә башкарылган һәм Тарафларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган очракта, Килешүгә карата барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр гамәлдә булып санала.

7.3. Килешү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә өзелергә мөмкин.

7.4. Әлеге Килешүдә каралмаган башка бөтен очракларда Тарафлар Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына таянып эш итәчәк.

7.5. Әлеге Килешү Тарафларның һәркайсы өчен берәр, бертөрле юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде.

7.6. Әлеге Килешүгә карата барлык кушымталар аның аерылгысыз өлеше булып санала.

## 8. Тарафларның юридик адреслары һәм банк реквизитлары

| | |
|---|---|
| Министрлык:<br>Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы<br>Адресы: 420111, ТР, Казан ш., Дзержинский ур., 10<br>ИНН 1654022967<br>КПП 165501001 | Алучы:<br>Юридик адресы:<br>Фактик адресы:<br>ОГРН<br>ОКПО<br>ИНН<br>КПП |
| Банк реквизитлары:<br>Р/с 40201810900000000002<br>ТР буенча ФКУ (ТР ФМ л/с 02092011000<br>(ТР Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, ЛБ007130001-ТАhТКХМАп))<br>БИК 049205001<br>Тел.: (843) 231-14-14 | Банк реквизитлары: |
| Министр<br><br>__________________/И.Ә. Фәйзуллин/<br>м.у. | Алучы<br><br>________________________________<br>м.у. (имза, Ф.И.А.) |

________________
№_____ Килешүгә карата
1 кушымта

Түбәндәге чараны оештыруга һәм үткәрүгә карата
чыгымнар сметасы

________________________________________________________________
(*чараның исемен күрсәтергә*)

| № п/п | Сарыф итү төрләре буенча чыгымнарның исеме | Бәясе, сум | Күләме | Суммасы, сум |
|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | |
| 2. | | | | |
| … | | | | |
| Җәмгысе | | | | |

Министрлык

Министр

_____________ / ___И.Ә.Файзуллин___
М.У.

Алучы

____________________________________
____________________________________
(вазифасы)

_______________ / __________________
М.У.(имза, Ф.И.А.)

__________________
№______ Килешүгә карата
2 кушымта

Субсидияне тоту турында хисап

сум

| № п/п | Фактта финансланды | Касса чыгымы | Акчаның тотылмыйча калган өлеше | Дәлилләүче документлар исемлеге (номеры, датасы) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Министрлык

Министр

_______________ / И.Ә.Фәйзуллин
М.У.

Алучы

________________________________________
________________________________________
(вазифасы)

___________________ / ______________________
М.У.(имза, Ф.И.А.)

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалык
министрлыгының 2015 елның
15 июнендәге 91/о номерлы
боерыгы белән расланды

Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә күргәзмәләр, корылтайлар, конференцияләр, симпозиумнар, съездлар оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплау өчен юридик затка Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия алу өчен

**гариза**

түбәндәгеләр өчен____________________________________________________
*(чараның исемен күрсәтергә)*

1. Мөрәҗәгать итүче оешманың аталышы, ИНН: ______________________________
_______________________________________________________________________

2. Адресы: ____________ ______________________________________________
(индекс) (юридик адресы)

________________ ________________ ____________________________________
(телефон) (факс) (E-mail)

3.Оешма җитәкчесенең Ф.И.А.: ___________________ тел.: _____________

4. Мөрәҗәгать итүче оешма башкара торган эшчәнлек төрләре турында мәгълүмат:
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________

5. Башкарылган чараларның юнәлеше: ________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________

6. Элемтә өчен мәгълүмат: _______________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________

7. Субсидия күчерү өчен реквизитлар: ____________________________________

_________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

Әлегесе белән шуны җиткерәм, гаризада күрсәтелгән барлык мәгълүмат, шулай ук өстәмә материаллар дөрес һәм төгәл, һәм вәкаләт бирелгән органның бездән һәм дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарыннан тапшырылган мәгълүматларны тәгаенләүче белешмәләр соратып алу хокукын раслыйм.

Кушымта:

1. Чараны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар барлыгын раслый торган документлар;
2. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча кредит әҗәте юклыгын раслый торган документ;
3. Устав күчермәсе;
4. Элегрәк бирелгән бюджет акчаларын максатсыз һәм/яки нәтиҗәсез куллану очраклары юклыгын раслый торган документ;
5. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт теркәвенә алынуы турында таныклык;
6. Мөрәҗәгать итүчене салым органында исәпкә кую турында таныклык;
7. Бердәм юридик затлар реестрыннан өземтә.

Җитәкче ____________________ / __________________________ /
(имза) (ФИА)

М.У.

Дата: __________________

2006 елның 27 июлендәге “Шәхси мәгълүматлар турында” 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә каршы түгелмен.

Җитәкче ____________________ / __________________________ /
(имза) (ФИА)

М.У.

Дата: __________________

| Вәкаләтле орган тарафыннан тутырыла |
| --- |
| Теркәү номеры __________________Датасы _______ |
| Татарстан Республикасының<br>Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |